| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апреля 2021 с. Тюлячи № 177

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 444 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә – хезмәткәрләргә түләү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 444 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә – хезмәткәрләргә түләү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән акчалата түләү бирү тәртибендә:

- 3 пунктны түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3. Яшь белгеч - Россия Федерациясенең 35 яшькә кадәрге, («Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш) төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) һөнәри белем бирү программалары буенча укуларын тәмамлаган, алган квалификация нигезендә беренче тапкыр эшкә урнаша торган гражданин.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин